| СОВЕТ<br>СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>КЫР ШОНТАЛЫ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

07.08.2020 Кыр Шунталы авылы № 120

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»
2018 елның 16 ноябрендәге 78 номерлы
Алексеевск муниципаль районының
Кыр Шунталы авыл җирлеге Советы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 407 маддәсендәге 6 пунктына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Алексеевск районы прокуратурасының 2020 елның 14 июлендәге 02-08-03 номерлы протестын үтәү йөзеннән Кыр Шунталы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2018 елның 16 ноябрендәге 81 номерлы Алексеевск муниципаль районының Кыр Шунталы авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге эчтәлекле үзгәреш кертергә: 4 пунктның 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Салым ташламасына хокукы булган физик зат салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза бирә, шулай ук әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән, аның салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы».

2. Әлеге карар, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет челтәрендә рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Алексеевск муниципаль районының
Кыр Шунталы авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Ф.Я.Хамадеев